ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮЧЕ
ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ МӘГАРИФ ОЕШМАСЫ
«ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ТАТАР ТЕЛЕ БУЕНЧА

ТӨП ДӘҮЛӘТ ИМТИХАНЫНА ӘЗЕРЛӘНҮ ӨЧЕН БИРЕМНӘР


ТАТАССР
Празднование 100-летия
Татарской АССР
Татарстан АССР төзелүнең
100 еллыгын бәйрәм итү
1920-2020


ПОБЕДА!
1945–2020

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ
ӨСТӘМӘ ПРОФЕССИОНАЛЬ БЕЛЕМ БИРҮ ДӘҮЛӘТ АВТОНОМ
МӘГАРИФ УЧРЕЖДЕНИЕСЕ «ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӘГАРИФНЕ ҮСТЕРҮ ИНСТИТУТЫ»

ТАТАР ТЕЛЕ БУЕНЧА ТӨП ДӘҮЛӘТ ИМТИХАНЫНА ӘЗЕРЛӘНҮ ӨЧЕН БИРЕМНӘР

КАЗАН
2020

ББК 74.202
Т 12

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы белән килешенеп,
«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә профессиональ белем бирүче дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең
гыйльми советы карары нигезендә басыла

Гомуми редакция:
Ногманова Л.Н., Татарстан Республикасы
Мәгарифне үстерү институты ректоры, педагогия фәннәре докторы;
Яковенко Т.В., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының
фәнни һәи инновацион эшчәнлек буенча проректоры,
педагогика фәннәре кандидаты

Рецензентлар: Зиннатуллин Р.К., Казан шәһәре мәгариф идарәсе методисты; **Җамалетдинова З.И.,** Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының башлангыч һәм мәктәпкәчә белем бирү кафедрасы доценты, педагогика фәннәре кандидаты.

Төзүчеләр:

Шәмсетдинова Р.Р., Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институтының татар теле һәм әдәбияты кафедрасы мөдире, филология фәннәре кандидаты, доцент;

Гыйлаҗева Л.Г., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты;

Фәттахова Р.Ф., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы доценты, филология фәннәре кандидаты;

Хадиева Г.В., татар теле һәм әдәбияты кафедрасы өлкән укытучысы.

Татар теле буенча төп дәүләт имтиханына әзерләнү өчен биремнәр/ төз.: Р.Р. Шәмсетдинова, Л.Г. Гыйлаҗева һ .б.— Казан: ТРМҮИ, 2020. —47 б.

Җыентык төп гомуми белем бирү программасын үзләштергән 9 нчы сыйныф укучыларына татар теленнән төп дәүләт имтиханына әзерләнергә ярдәм итү максатыннан төзелде. Хезмәт контроль бәяләү материалларының үрнәк вариантларына таянып башкарылган өстәмә материал формасында тәкъдим ителә. Имтихан эшенең күрсәтмә вариантына аңлатма, язма эшне бәяләү критерийлары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы сайтыннан (http://mon.tatarstan.ru/) алынды.

©ТРМҮИ, 2020

ТАТАР ТЕЛЕ
81 нче код биремнәре

Имтихан эшенең күрсәтмә вариантына аңлатма

Дәүләт йомгаклау аттестациясе эше сочинение элементлары белән киңәйтелгән иҗади биремле изложение формасында тәкъдим ителә. Изложение имтихан бирүчеләрнең тыңланган текстка нигезләнеп, мөстәкыйль рәвештә мәгънәви бөтен, сөйләм бәйләнешлелеге һәм язу эзлеклелеге белән характерланган иҗади бирем башкаруына йөз тота. Киңәйтелгән изложение укучыларның лингвистик компетенциясе (тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алуы, тел һәм сөйләмгә караган белеме, өйрәнгән материалны урынлы куллана белү күнекмәләре, шулай ук танып белү, төркемләү, татар теле дәресләрендә алган аналитик белем һәм күнекмәләр), тел компетенциясе (лексик, грамматик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклау осталыгы һәм күнекмәләре), коммуникатив (аралашу) компетенциясе (сөйләм эшчәнлегендә продуктив һәм рецептив күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәсе) тикшерелә. Күрсәтмә материаллар катнашучыга һәм киң җәмәгатьчелеккә дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенең төзелеше, биремнең үзенчәлеге, аның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бу вариантагы биремне үтәүнең бәяләү критерийлары җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра. Күрсәтмә материаллар чыгарылыш сыйныфта дәүләт йомгаклау аттестациясе эшенә әзерлек осталыгын булдырачак.

Эшне үтәү өчен күрсәтмә

Татар телендә гомуми белем бирү оешмаларының IX сыйныфын тәмамлаучы укучыларга татар теленнән дәүләт йомгаклау аттестациясе эшен язу өчен 3 сәгать 55 минут вакыт бирелә. Бирем 1 өлештән тора. Укучылар текстны 2 тапкыр тыңлыйлар. Беренче тапкыр тыңлаганнан соң караламада эшләү өчен вакыт бирелә (5 минут). Текстны икенче тапкыр тыңлаганнан соң, изложение язу эше башлана. Изложение, биремдә күрсәтелгән проблемага нигезләнеп, сочинение элементлары кулланып, киңәйтелергә, ягъни укучылар әлеге проблемага бәйле иҗади фикер йөртергә һәм үз фикерләрен дөрес, логик эзлеклелектә формалаштырып язырга тиеш. Язма эшне башкару барышында орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт бирелә. Караламадагы язулар тикшерелми! Язма эш махсус төзелгән критерийлар буенча бәяләнә. Язма эшне хаталарсыз башкарып, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

Сезгә уңышлар телибез!

1 нче вариант

Текстны укыгыз, микротемалар белән танышыгыз. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Язма эш изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага нигезләнеп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Намус

Борын-борын заманда бер бабай яшәгән. Балалары күп булган. Алар бергәләп басуда эшләгәннәр, бергә утырып ашаганнар, хәсрәтләрен һәм шатлыкларын җыйнаулашып уртаклашканнар. Шуңа күрә бу гаилә нужа күрмәгән, тату гына гомер иткән.

Көннәрнең берендә бабай иртән торып тышка чыкса — бөтен дөнья ап-ак карга күмелгән. Шулвакыт ат абзарының капкасы янында ниндидер ят эзләрне күреп алган. Кунак-фәлән килмәде, балалар бар да өйдә йоклап яталар, дип аптырашта калган бабай. Күп уйлап тормаган, эз буйлап киткән.

Капкасын ачып, урамга чыккан, авыл аша узган, басуга барып җиткән. Эз басу уртасындагы гөлҗимеш куагы янында юкка чыккан.

Бабай куак каршына килеп баскан да:

— Бүген берәү, өйдән чыгып, монда килгән. Эндәш! Кем син? — дигән.

— Өеңне мин ташлап чыктым. Мин — синең Бәхетең. Инде эзләп тапкансың икән, әйт, җаныңа кайсы якынрак: малмы, җирме, затлы киемме? Шул теләкләреңнең берсен генә үтим дә башка йортка күчәм.

— Бер үтенечем бар: кайтып, гаиләм белән киңәшергә рөхсәт ит, — дип сораган бабай.

— Тизрәк әйләнеп кил. Көтәрмен, — дигән Бәхет.

Бабай, ашыгып өенә кайткан һәм гаиләсенә Бәхет китүен һәм аның бабайга куйган шарты турында сөйләп биргән.

Бергәләп киңәш корганнар. Өлкән кеше буларак, үз теләгән башта бабайның карчыгы әйткән:

— Күбрәк җир сора, мул уңыш җыеп алырбыз, тамагыбыз тук булыр, —дигән.

— Бәлки, чаптар атлар сорарсың? — дип киңәш иткән өлкән улы.

— Затлы кием һәм муенсалар бүләк итсә, яхшы булыр иде, — дип, сүзгә кушылганнар бабайның кызлары.

Моңа кадәр яшь киленнең бервакытта да башкалар сүзенә катнашканы булмаган. Көтмәгәндә ул да тавыш биргән:

— Намус сорасаң, яхшы булыр иде, әткәй, — дигән.

— Бик дөрес әйтәсең, килен, — дип шатланган бабай.

— Шундый матур теләк нигә минем башыма килмәде икән? — дигән бабайның карчыгы. Уллары белән башка киленнәре дә бу теләкне бик хуплаганнар. Бабай басудагы куак янына чапкан.

— Бик озак киңәштегез, я, гаиләң ни сайлады? — дип сораган Бәхет.

— Малны да, җирне дә, киемне дә ал. Тик, зинһар өчен, Намусны калдыра күр, — дип җавап биргән бабай.

— Болай булгач, өегезгә кире кайтам. Намус кайда, мин шунда бит, — дигән Бәхет.

Бәхет әйләнеп кайткач, бабайның гаиләсе элеккеге кебек нужа күрми, тату яшәгән.

(Балкар халык әкияте) (438 сүз)

Чыганак: «Намус» дип аталган балкар халык әкияте.

«Намус кайда, мин шунда бит, — дигән Бәхет», — җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме 200 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Бабайның гаиләсе тату гына гомер иткән.
2	Бабай ят эз күрә.
3	Бәхет бер теләкне үтәргә сүз бирә.
4	Бабай гаиләсе белән киңәшләшә.
5	Бәхет кире бабай өенә кайтып китә.

2 нче вариант

Текстны укыгыз, микротемалар белән танышыгыз. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Язма эш изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага нигезләнеп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Хәтеремдә: ул көн болытлы иде. Аз гына яңгыр сибәләп тора. Тирә-якта Белоруссия кыры. Урылмаган игеннәрнең башлары түбән иелгән. Алар шулай моңланып, җирнең кайгылы зарын тыңлап торалар кебек. Юл буенда һәм кырда янган машиналар, танклар аунап ята. Күз күреме җитә алган һәр җирдә окоплар, базлар һәм балчык өемнәре зур-зур каберләргә охшап торалар. Урманнар өстендә төтен болытлары асылынган, янып каралган агачлар күңелгә авыр моң салалар.

Без юл читеннән барабыз. Ә юлдан немец танклары, солдатлар төялгән машиналар уза. Менә бик түбәннән генә самолёт очып үтә, колоннаны буйдан-буйга күзәтеп уза.

Минем белән янәшә баручы бер иптәш:

— Безнең өстә очарга зур кыюлык кирәкми, син әнә тегендә, фронтка бар, канатыңны өтеп җибәрерләр иде синең, — ди.

— Юк шул, юк, өтмиләр. Өтсәләр, биредә киерелеп очып та йөрмәс иде ул. Күрәсең, алар көчле әле, — ди икенче иптәш.

Сүз шуннан артыкка сузылмый. Кем көчле дә кем көчсез — хәзер каян беләсең? Хәзер бу турыда сөйләшүнең нигә кирәге бар? Без инде әсирләр. Безне каядыр алып баралар. Яралылар, хәлләре бетеп, һаман артка кала баралар. Ахырында, тәмам көчсезләнеп, юлга егылалар. Кинәт мылтык тавышы ишетелеп китә — юл читендә безнең дус, җирне кочаклап, күзләрен йома. Колонна алга узган саен, юлда ятып калган солдат гәүдәләре күбәя бара.

Менә алда кечкенә генә авыл күренде. Дөресрәге, кайчандыр авыл булган да, хәзер инде нигезе генә калган утырып. Янып күмергә әйләнгән өйләр урынында, кабер ташлары кебек тырпаеп, шәрә мичләр утыра. Авылда җан әсәре күренми.

Колонна килеп җитәрәк, каяндыр шунда җимерекләр арасыннан бер әби белән бер кечкенә генә кыз килеп чыкты. Әбинең кулында чиләк, ә кыз кружка тоткан иде. Алар безгә су алып

чыккан булганнар. Яннан атлаган немец солдаты йөгереп барды да әбинең чиләген тибеп аударды, кызның кулыннан кружканы алып, аяк астына салып таптады һәм кычкыра-кычкыра, әбине дә, кызны да куарга тотынды. Әби тиз генә китмәде. Яулыгының чите белән күзләрен сөртә-сөртә:

— Улларым, балакайларым! Бер Ходай гына сезне коткарсын инде, — диде.

Бу карт ананың сүзләре әле дә минем исемдә. Бүген дә аның кайгылы йөзе күз алдымда тора. Рус анасы безгә үзенең иң соңгы ярдәмен күрсәтергә теләде. Бәлки, икенче көнне ул үз өенең кисәүләре өстенә ятып үлгәндер. Аның туфрагы каршында мин бүген башымны иям. Кайда син, нәни кыз? Мин сине, әгәр бүген очратсам, инде танымам. Шулай да мин сине оныта алмыйм. Әгәр исән булсаң, бәхетле яшә, аппагым! Синең нәни кулларыңнан без су эчә алмадык. Ләкин без ул авыр минутларда, сезне күргәч, күпме шатлык кичердек. Без туган илдә онытылмаган идек...

(Н. Дәүли) (387 сүз)

Чыганак: Нәби Дәүлинең «Яшәү белән үлем арасында» әсәреннән өзек.

«Без ул авыр минутларда, сезне күргәч, күпме шатлык кичердек. Без туган илдә онытылмаган идек...» — җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме 200 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Тирә-якта Белоруссия кыры.
2	Әлегә дошман көчле.
3	Әсирләрне каядыр алып баралар.
4	Җимереклеләр арасыннан әби белән кыз килеп чыкты.
5	Без туган илдә онытылмаган идек.

3 нче вариант

Текстны укыгыз, микротемалар белән танышыгыз. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Язма эш изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага нигезләнеп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм таныpлык итеп языгыз.

Туган телебез турында «Тел күрке — сүз» дигән тапшыруны башлап җибәргәннән соң, радиога хатлар ява башлады. Һәр кайсысында диярлек иптәшләрнең туган телебезне кайгыртулары сизелеп тора. Алар телебезгә кагылышлы әйбәт тәкъдимнәрен язалар, сораулар бирәләр. Бу бик күңелле хәл.

Мәкаләбездә без шул сорауларның берсенә җавап бирәчәкбез. Менә берничә хатта мондыйрак сорау бар: «Язганда яки сөйләгәндә чит тел сүзләре кушып телебезне бозмыйбызмы?» — дигәннәр.

Башта ук бер нәрсәне ачыклап китик: татарча «тел бозу» дип сөйләнсә дә, татар теле дигән гомуми телебезгә бу һич тә кагылмый, чөнки гомуми телне «бозып» булмый. Чыннан да, менә мин әле шушы тел белән сөйлим икән, мин аның матур да, камил дә, бай да икәнлегенә сокланып, күңелемдәге уйларымның, хисләремнең һәммәсен әйтә алуыма горурланып сөйлим. Ул телне мин ясамаган. Мин аны боза да алмыйм! Әгәр мин, мәсәлән, «әгәр» диясе урынга «если» дисәм, «чөнки» урынына «птамушты» дип сөйләсәм, моңардан гомуми татар теле «бозылу» түгел — селкенми дә, чөнки, телне белеп сөйләшкәннәр сөйләшсен өчен, аның «чөнки»е дә, «әгәр»е дә үз урынында кала. Алар — зур туган телебезнең һич бозылмас энҗеләре. Халык ни гомер яшәсә — теле дә шул гомер яшәячәк.

Димәк, радиога хат язган иптәшләрнең: «Чит тел сүзләре кушып, телебезне бозмыйбызмы?» — дип борчылулары телгә түгел, ә аерым кешеләрнең сөйләм теленә кайтып кала. Шуңа күрә мин «тел бозу» дигәндә нәкъ шул мәгънәсен генә күз алдында тотачакмын.

Чыннан да, без үзебезнең диңгездәй зур, тирән телебездән җитәрлек дәрәҗәдә файдаланабызмы соң? Үзебезнең гөл кебек сүзләр бар килеш, һич кирәкмәстән башка тел сүзләрен

кулланмыйбызмы? Кызганычка каршы, «Юк!» дип җавап бирә алмыйбыз.

Мәгәр «тел бозу» әле ул кирәкмәгәнгә чит тел сүзләрен кыстырып сөйләү генә түгел. Әгәр үз телеңнең грамматик нормаларын җимереп сөйләшсәң, үз сүзеңнең дә чит булуы бар.

Гомумән, без нинди тел белән сөйләшсәк тә, аның сүзләрен дә, грамматик кануннарын да бозмыйча, дөрес итеп сөйләшергә тиешбез. Аны бозуларга юл куймаска, көрәшергә тиешбез. Ләкин — нинди юллар белән?

Күптән түгел мин газетадан бер мәкалә укыган идем. Франциядә «Француз теленең сафлыгын саклау турында» закон чыгарганнар. Шул закон нигезендә рәсми кәгазьләрдә чит тел сүзләрен кулланган өчен 80 нән алып 160 франкка кадәр штраф салыначак икән. Француз лингвистлары әйтүенчә, бу закон француз телен чит сүзләр белән чүпләнүдән саклау өчен чыгарылган, ди.

Бик кызыклы факт бу! Ләкин, алда әйтеп үткәнемчә, бер телдән икенче телгә сүзләр керүне боерыклар белән, законнар белән генә тыеп булмый. Бу — аптыраганнан эшләнгән вакытлы бер чара гына.

Минемчә, телне бозмыйча, дөрес итеп, фикереңне җиткереп сөйләшү ул — кешенең әдәп, культура билгесе.

(Х.Сарьян) (381 сүз)

Чыганак: Хәсән Сарьянның «Тел белмәгән — теленнән абыныр» мәкаләсеннән өзек.

«Радиога хат язган иптәшләрнең: «Чит тел сүзләре кушып, телебезне бозмыйбызмы?» — дип борчылулары гомумән телгә түгел, ә аерым кешеләрнең сөйләм теленә кайтып кала» — җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме 200 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	«Тел күрке — сүз» дигән тапшыруга килгән хатлар.
2	«Язганда яки сөйләгәндә, чит тел сүзләре кушып телебезне бозмыйбызмы?» эчтәлектәге хатлар.
3	Чит тел сүзләре кушып сөйләшү аерым кешеләрнең сөйләм теленә кайтып кала.
4	Үз телеңнең грамматик нормаларын җимереп сөйләшү дә тел бозу булып санала.
5	Франциянең тел сафлыгы өчен көрәш мисалы.
6	Телне бозмыйча, дөрес итеп сөйләшү ул — кешенең әдәп, культура билгесе.

4 нче вариант

Текстны укыгыз, микротемалар белән танышыгыз. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Язма эш изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага нигезләнеп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Хуҗаларга кунаклар да еш кына килгәлиләр иде. Өйдә, билгеле, ыгы-зыгы башлана. Гөлбикәнең кадак үкчәле туфлиләре белән шак-шок басып, ашыгып йөргәне, савыт-саба тавышлары ишетелә, шуннан залдагы кунакларның шаулап сөйләшүләре, көлүләре ишетелә башлый. Карчык шуларның барысын да ничектер балаларча кызыксынып тыңлап ята. Сөйләшеп-көлешеп арыгач, берәрсе пианинода уйный башлый, аңа кушылып, кемдер җырлап та җибәрә. Ә кайчагында исә кунакларның тавышы бөтенләй тына, аның урынына ят бер хатын-кызның сөйләгән тавышы ишетелә. Бу инде телевизор дигән нәрсә булырга тиеш. Карчыкның аны әле күргәне юк, ләкин шундый әкәмәт бер әйбер барлыгын, өйдәгеләрнең аны бик көтеп, бик яратып карауларын ул инде белә. Вакыт-вакыт шул «телевизор» дигән нәрсәдән бик моңлы курай тавышы да, бик борынгы башкорт җыры да яңгырый... Шул чакта карчык ишекләрне ачарга куша һәм җанына тансык бу җыр-моңны тәмам эреп, хыялларга китеп тыңлый. Гүя ул ефәк кылганнар йөгерешкән даласына, авыр чулпыларын чыңлатып йөргән кыз чакларына кайткандай була.

Кунакларның күбесе читтәге кечкенә бүлмәдә авыру карчык ятканны белмиләр дә иде шикелле... Һәрхәлдә, авыру бар дип борчылучы яки аның хәлен белергә керүче булмый диярлек — утыралар, көләләр-шаулыйлар, ашыйлар-эчәләр дә таралышалар... Шулай да ешрак килеп йөрүче бер кунак Акъәби янына кергәли торган иде. Бу — тәбәнәк буйлы, ашыкмыйча, елмаеп кына сөйләшүче, исеме шактый билгеле булган олы яшьтәге шагыйрь иде.

Залда кунаклар шаулап утырган чакта гына, ул карчык янына мыштым гына килеп керә, керә дә: «Саумы, әбекәем!» — дип ике куллап күрешә, аннары урындык алып, карават кырына утыра. Ул күп сөйләшергә яратмый иде, күбрәк тезләренә таянып

тик кенә утыра һәм ара-тирә берәр хикмәтле сорау гына биреп куя торган иде. Карчык бу уйчан, сәер кешене көтеп ала иде. Ничектер алар, аз сөйләшсәләр дә, бер-берсенә бик тиз ияләшеп киттеләр.

— Акъәби, Акъәби! — ди шагыйрь, үзалдына әйткәндәй әкрен генә. — Ә ни өчен Акъәби, ни өчен Кара әби түгел?

— Минем исемем Акбикә, — ди карчык, бу көтелмәгән сорауга бераз пошынып. — Кыз чагымда мине Аксылу дип йөртәләр иде, кияүгә чыккач, Аккилен булдым, аннары Акҗиңгә, ә хәзер менә Акъәби.

— Димәк, син гомерең буена ак кеше булгансың икән. Ак күңелле, пакь күңелле кеше... Менә миңа да шундый әсәй кирәк иде.

— Ни сөйлисең, улым, синең үз әсәең бардыр бит?

— Юк шул, юк... Күптән оҗмахта инде ул... Ә әсәйсез авыр, әсәй сабый балага гына түгел, менә минем кебек сакалы агарган кешегә дә кирәк икән ул!

— Рәхмәт, улым! — ди карчык, нигәдер ирене калтырый башлап.

(Ә. Еники) (368 сүз)

Чыганак: Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәреннән өзек.

«Ә әсәйсез авыр, әсәй сабый балага гына түгел, менә минем кебек сакалы агарган кешегә дә кирәк икән ул!» — җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме 200 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Хуҗаларга кунаклар еш килә.
2	Телевизордагы җырлар далага алып кайталар.
3	Олы яшьтәге шагыйрь карчык янына еш керә.
4	Карчык шагыйрьгә Аксылу, Акҗиңгә, Акъәби булуы турында сөйли.
5	Әсәйсез (анасыз) олы кешегә дә авыр.

5 нче вариант

Текстны укыгыз, микротемалар белән танышыгыз. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Язма эш изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага нигезләнеп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Мәрхәмәтле Төлке

Мескен Кошчыклар аянычлы һәм җан авырттыра торган тавышлары белән черелдәп, уянмас йокыга киткән аналарын уятырга тырышалар иде.

Бу хәлне, бу күренешне караган Кешенең, никадәр таш йөрәкле булса да, җаны ачыр һәм шәфкать каннары кайнарлык иде.

Берзаман Төлке, бу ятимнәрнең оясына якын килеп, шул оя яныннан үткән һәрбер Коштан бу үксезләргә мәрхәмәт итүләрен сорап, суфиланып утыра иде.

Югары, күренер-күренмәс әйләнеп очкан Тургайга карап: «И син, Тургай! Юкка буш һаваларда канат талдырып әйләнгәнче, бу атасыз-анасыз Балаларга игенлекләрдән, кырлардан бер-ике бөртек орлык булса да китереп бирсәң, нинди савап булыр иде!» — дия иде.

Шул тирәдә генә йөргән бер Чәүкәгә дә: «И Чәүкә дус! Синең балаларың әллә кайчан үсеп зур булдылар, инде алар үзләре дә үзләренә җитәрлек азык таба алырлар. Син инде менә бу тәрбия-челәре булмаган Карлыгач балаларына ана бул, аларны җылы мамыгың белән җылыт».

Шуннан пырхылдап очкан Чыпчыкка да: «Юкка чырылдап, пырхылдап йөргәнче, күз алдындагы бәхетсез Кошчыкларга Чебен, Чикерткә аулап ашатсаң, хисапсыз әҗерләр алыр идең. Анасызларга ана булып торсаң, боларның анасызлык кайгыларын оныттырыр идең», — дия иде.

Көннәр үтә. Белмим, Төлкенең нәсыйхәтләрен тыңлаучы булдымы, юкмы? Әмма баягы ятим Кошчыклар, ачлык, сусызлыкта тыныч утыра алмыйча, берзаман Төлкенең авыз төбенә үк егылып төштеләр. Хәзер без карыйк: Төлкенең сүзе белән эше

арасында нинди мөнәсәбәт бар икән? Төлке үзенең авызына төшкән бичара Кошчыкларны кычкыртып, черелдәтеп ашады да китте.

Укучы! Исең китмәсен, кем ки яхшылык хакында сөйләп, Кешеләрнең колагын тондырса, бел ки, ул Кеше икенче берәүнең кесәсеннән генә яхшылык итәргә яратучы буладыр.

Ул яхшы белә ки: аның үзенә ул яхшылыктан бер тиен дә зарар килми, әмма үз өлешенә бер изгелек итәргә тугры килсә, ул бөтенләй бу Төлке кебек буладыр.

(Г.Тукай) (259 сүз)

Чыганак: Габдулла Тукайның «Мәрхәмәтле Төлке» мәсәле.

«Укучы! Исең китмәсен, кем ки яхшылык хакында сөйләп, Кешеләрнең колагын тондырса, бел ки, ул Кеше икенче берәүнең кесәсеннән генә яхшылык итәргә яратучы буладыр» — җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме 200 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Мескен Кошчыкларның аналары үлгән.
2	Төлке агач төбендә кошчыкларны җәлләп утыра.
3	Төлке Тургайга эндәшә.
4	Төлке Чәүкәгә эндәшә.
5	Төлке Чыпчыкка эндәшә.
6	Төлке кошчыкларны ашый.
7	Икенче кеше хисабына яхшылык эшләргә теләүчеләр бар.

6 нчы вариант

Текстны укыгыз, микротемалар белән танышыгыз. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Язма эш изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага нигезләнеп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм таныpлык итеп языгыз.

Озакламый мин бу чәчәк турында күбрәк белдем. Нәни принц планетасында һәрвакыт бик гади, әллә ни күзгә бәрелеп тормаган чәчәкләр үскән. Таҗ яфраклары да аз икән. Шуңа күрә алар, күп урын алмыйча һәм беркемгә дә комачауламыйча, тыныч кына үсеп утыралар, ди. Бу чәчәкләр иртәләрен ачылалар, ә кич җитүгә сулалар икән.

Ә монысы кайдандыр, ничектер килеп эләккән орлыктан тишелеп чыккан. Башка бер үсентегә дә охшамаган бу шытымнан Нәни принц көннәр буе күзен ала алмый икән. Күп тә узмый, шытым, үсүдән туктап, чәчәккә бөреләнә. Нәни принцның әле беркайчан да бу кадәр зур бөре күргәне булмый. Ул, могҗиза көткәндәй, тынып кала. Ә билгесез кунак, үзенең яшел өенә яшеренгән килеш, һаман ыспайлана, бизәнә. Ул башта тырышып-тырышып буяулар сайлый. Аннары ашыкмый гына бер-бер артлы таҗ яфракчыкларын иңенә салып карый. Чәче-башы тузган ниндидер бер мәк чәчәгенә охшарга теләми ул. Бик тә чибәр булып күренәсе килә аның. Әйе, гаҗәеп кыланчык була ул! Көн артыннан көн үтә, чәчәк һаман бизәнә бирә. Ә беркөнне, кояш чыгып килгән вакытта, чәчәк таҗлары ачыла.

Бу мизгелне көтеп күпме көч түккән чибәркәй, иснәп куйганнан соң, болай ди:

— Уф, көчкә уяндым... Гафу итегез... Үземне тәртипкә китерергә дә өлгермәдем...

Нәни принцның шатлыгы эченә сыймый:

— Сез нинди гүзәл! — ди ул.

— Чыннанмы? — дигән җавап ишетә Нәни принц. — Шуны да онытмагыз, мин бит кояш белән бергә тудым.

Нәни принц бу гаҗәеп кунакның бик үк тыйнак түгеллеген аңлый, билгеле. Ләкин холкы нинди генә булса да, ул искиткеч матур!

Бераздан чәчәк тагын телгә килә:

— Тамак ялгарга вакыт бугай инде. Сез миңа ярдәм итмәссезме икән?..

Нәни принц уңайсызланып китә, аннары чишмә суы алып килеп чәчәккә сибә.

Бу сылукай горур һәм үпкәчел булып чыга. Нәни принцны тилмертеп бетерә ул.

— Мин бик тә җилдән куркам. Чаршавыгыз юкмы сезнең?

«Үзе үсемлек, ә үзе җилдән курка... бик сәер... — дип уйлый Нәни принц. — Нинди авыр холыклы бу чәчәк»...

Бу гүзәл чәчәкнең һәр сүзен тыңларга әзер торса да, озакламый Нәни принцның күңелендә икеләнү тойгылары уяна. Юк кына сүзләр дә аның җанын рәнҗетә. Тиздән ул үзен бик бәхетсез итеп сизә башлый.

— Аның сүзләрен юкка тыңлаганмын мин, — диде ул миңа бервакыт. — Беркайчан да чәчәкләр сөйләгән сүзгә игътибар итәргә ярамый икән. Чәчәкләргә карап сокланырга, аларның хуш исләрен иснәргә генә кирәк икән. Минем чәчәгем бөтен планетага хуш ис таратты, ә мин шуңа шатлана да белмәдем. Ул чакта мин берни дә аңламаганмын! Сүзгә түгел, эшкә карап фикер йөртергә кирәк булган. Ул миңа үзенең хуш исен бүләк итте, тормышымны бизәде. Качарга кирәкми иде миңа! Аның гөнаһсыз хәйләләре бары назлану икәнен аңламаганмын.

(Антуан де Сент-Экзюпери , Р.Вәлиев тәрж.) (383 сүз)

Чыганак: Антуан де Сент-Экзюпериның «Нәни принц» әсәреннән өзек.

«Ул чакта мин берни дә аңламаганмын! Сүзгә түгел, эшкә карап фикер йөртергә кирәк булган» — җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме 200 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Нәни принц планетасында һәрвакыт бик гади чәчәкләр үскән.
2	Кайдандыр килеп эләккән орлыктан гүзәл гөл тишелеп чыккан.
3	Гөл бик матур була.
4	Гөл Нәни принцны тилмертеп бетерә.
5	Нәни принц үзен бик бәхетсез итеп сизә башлый.
6	Нәни принц гөлдән качып китүенә үкенә.

7 нче вариант

Текстны укыгыз, микротемалар белән танышыгыз. Тулы текстның һәм андагы микротемаларның төп эчтәлеген бирергә кирәклеген истә тотып эшләгез. Язма эш изложение текстыннан соң, текстта күтәрелгән проблемага нигезләнеп башкарыла. Язма эшнең күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш. Эшегезне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

...Көне... Иртәнге сәгатьтән үк бөркү эсселек үзен шул чаклы сиздерә дә башлар икән. Гаҗәп! Хәтта төне дә җиңеллек китермәде — суынырга өлгермәгән таш йортлардан, таш урамнардан, тузан исен аңкытып һаман бөркелеп торды бу китмәскә килгән эсселек... Менә өч атна инде яңгыр тамганы юк. Температура көндезен утыздан артып китә, төннәрен егермедән дә төшми диярлек. Бер кат җәймә генә ябынып ятсаң да йоклап китә алмыйча азапланып бетәсең, мендәреңнең салкынчарак җирен эзләп, аны кат-кат әйләндерергә мәҗбүр буласың. Кышкы суыктан да әшәкерәк икән ул бөркү эсселек!..

Гасыйм Сәләхович та шәрә килеш диярлек киң караватының читенә таянып, күзләрен дә ачарга иренеп, тик кенә утыра. Әллә ялкаулыктан, әллә хәлсезлектән? Икесе дә бардыр ахрысы. Шулай да ялкаулыгы хәлсезлектән иде. Хәлсез булганга күрә аның кыл да кыймылдатасы килми иде, чөнки ул бик начар йоклады, тирләдепеште, әйләнде-тулганды — һаман да шул әшәке эсселек аркасында. Әмма сәбәп бер аңарда гына түгел иде шикелле... Төп сәбәп йөрәгендә булса кирәк — йөрәге таза түгел иде Гасыйм Сәләховичның...

Менә хәзер дә ул, караватыннан кузгалырга кыймыйча, гүя йөрәгенә колак салып утыра. Нишли, ничегрәк «тота» ул үзен — тәндәге тере җан? Көйсезләнмиме, ялгышмыймы, хәрәкәт итүе ничегрәк? Шуны әйтергә кирәк, соңгы вакытларда йөрәге аның нәкъ менә йоклаганда яки уянгач үзен ныграк сиздерә башлады. Нидән, ни өчен?.. Бүгенгесен бөркү һава, начар йокыдан да күрергә мөмкин, ә башка көннәрдә? Бу хәл, билгеле, Гасыйм Сәләховичны борчый, кәефен боза, куркытып та куя иде. Ярамый бит болай, ди ул үз-үзенә җитди бер хәтәрне сизгәндәй, һәм бөтен эшен ташлап бүген үк врачка күренергә кирәк дигән карарга да килә. Ләкин шулай дисә дә, ул бармый-күренми, чөнки эшеннән аерыла алмый,

ә врачка бару үзе бер мәшәкать, аннары — иң гаҗәбе — йөрәк үзе дә тәмам тынычлана, «хуҗасын» бер дә диярлек борчымый башлый. Гүя «хуҗасының» эше, хәрәкәте, кайгысы аңа да күчә, ул да шуларга көйләнә, җайлаша, гүя үзен юри оныттырып тора. Кыскасы, яраклаша белә йөрәк кешегә!

Тик менә кеше үзе еш кына йөрәге белән хисаплашмый. Борчый, җәберли, оныта бичараны еш кына! Сәбәпләре моның кырык төрле — санап кына чыгарлык та түгел. Гадәттә, кешенең үзен гаеплиләр, «саклый белмәде йөрәген» диләр.

Әмма кеше үзе генә саклый ала микән соң аны? Иң элек кешенең үзен сакларга кирәк түгелме икән?

(Ә. Еники) (345 сүз)

Чыганак: Әмирхан Еникинең «Тынычлану» хикәясеннән өзек.

«Әмма кеше үзе генә саклый ала микән соң аны? Иң элек кешенең үзен сакларга кирәк түгелме икән?» — җөмләсендә әйтелгән фикерне ничек аңлыйсыз? Шулар турында языгыз. Фикерегезне раслау өчен, матур әдәбияттан һәм тормыш тәҗрибәгездән **2 мисал** китерегез.

Язма эшнең күләме 200 сүздән дә ким булмаска тиеш.

Язма эшне чиста һәм танырлык итеп языгыз.

Тыңланган текстка таянып язылмаган эшкә билге куелмый.

Текстның эчтәлеген аңлатмаларсыз язган һәм сочинение элементлары белән киңәйтмәгән очракта 0 балл куела.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Өч атна инде яңгыр тамганы юк.
2	Гасыйм Сәләхович төнлә йоклый алмады.
3	Йөрәкне табибка күрсәтергә кирәк, ләкин Гасыйм Сәләховичның вакыты юк.
4	Гадәттә, йөрәге авыртуда кешенең үзен гаеплиләр.
5	Йөрәкне ничек сакларга?

Язма эшне бәяләү критерийлары

1 нче таблица

№	Критерий	Балл
ИК1	**Изложениенең эчтәлеге**	
	Укучы тыңлаган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган барлык мәсьәләләр язмада урын алган	**2**
	Текстның эчтәлеге ачылган, әмма бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән).	**1**
	Текстның эчтәлеге ачылган, әмма бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән).	**0**
ИК2	**Изложениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге**	
	Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә: — логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган; — текст кызыл юлларга дөрес бүленгән.	**2**
	Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә, әмма бер логик хата бар яки кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар.	**1**
	Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган, әмма бердән артык логик хата яки кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән.	**0**
ИК3	**Эшнең композицион бөтенлеге**	
	Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк.	**2**
	Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, ләкин текст төзүдә 1 хатасы бар.	**1**
	Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар.	**0**
ИК4	**Дәлил-мисалларның булуы**	
	Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (**матур әдәбиятка караган 2 дәлил-мисал** китергән).	**4**
	Укучы **2 дәлил-мисал** китергән, шуларның берсе **матур әдәбиятка** карый.	**3**
	Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып, 2дән ким булмаган дәлил китергән)	**2**

	Укучы 1 дәлил-мисал китергән.	**1**
	Укучы әлеге кисәкнең эчтәлеген аңлата торган дәлил-мисал китермәгән, яки укучы биремдәге цитатаны я аның бер өлешен дәлил-мисал итеп китергән.	**0**
ИК1-ИК4 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл		**10**

Игътибар! Әгәр изложениедә сочинение элементлары булмыйча, текстның эчтәлеге генә чагылыш тапса, бәяләүнең барлык критерийлары буенча (ИК1-ИК4) 0 балл белән бәяләнә. Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге аерым бәяләнә (2 нче таблицаны кара).

2 нче таблица

№	**Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары**	
ГК1	**Орфографик нормаларның үтәлеше**	
	Орфографик хаталары юк яки хатасы 1дән артык түгел.	**2**
	2–3 хата җибәрелгән.	**1**
	Хаталарының саны 4тән артык.	**0**
ГК2	**Пунктуацион нормаларның үтәлеше**	
	Пунктуацион хаталары юк яки хатасы 2дән артык түгел.	**2**
	3–4 хатасы бар.	**1**
	Хаталарының саны 5 тән артык.	**0**
ГК3	**Грамматик нормаларның үтәлеше**	
	Грамматик хаталары юк яки 1 хатасы бар	**2**
	2 хатасы бар.	**1**
	Хаталарының саны 3 тән артык.	**0**
ГК4	Сөйләм нормаларының үтәлеше	
	Сөйләм хаталары юк яки хатасы 2дән артык түгел.	**2**
	3–4 хатасы бар.	**1**
	Хаталарының саны 5 тән артык.	**0**
ФК1	Язма сөйләмнең фактик төгәллеге.	

	Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк.	**2**
	Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар.	**1**
	Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар.	**0**
ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча изложение өчен иң югары балл		**10**

Грамоталылыкны бәяләгәндә, изложениенең күләмен исәпкә алырга кирәк. Язма эшнең гомуми күләме 200 сүздән ким булмаска тиеш.

2 нче таблицада китерелгән нормативлар гомуми күләме 200 дән артык сүз булган изложениеләрне тикшерү өчен кулланыла.

Әгәр изложениенең гомуми күләме 150–199 сүз булса, ГК1-ГК4 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый:

ГК — 1 буенча орфографик хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК — 2 буенча пунктуацион хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК — 3 буенча грамматик хаталар булмаганда 1 балл куела;

ГК — 4 буенча сөйләм хаталары булмаганда 1 балл куела.

Әгәр изложениенең гомуми күләме 100 сүздән артмаса, мондый эшләргә ГК1-ГК4 критерийлары буенча 0 балл куела.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен тулаем башкару барышында җыярга мөмкин булган максималь балл — 20.

ТАТАР ТЕЛЕ
82 нче код биремнәре

Аңлатма язуы

2020 нче елгы төп дәүләт имтиханын изложениене сочинение элементлары белән киңәйтеп язу формасында үткәрү тәкъдим ителә. Киңәйтелгән изложение укучыларның лингвистик компетенциясен (тел материалы белән эшләгәндә, лингвистик белемнәрне куллана алуы, тел һәм сөйләмгә караган белеме, өйрәнгән материалны урынлы куллана белү күнекмәләре, шулай ук танып белү, төркемләү, татар теле дәресләрендә алган аналитик белем һәм күнекмәләр), тел компетенциясен (лексик, грамматик, стилистик, орфографик һәм пунктуацион нормаларны саклау осталыгы һәм күнекмәләре), коммуникатив (аралашу) компетенциясен (сөйләм эшчәнлегендә продуктив һәм рецептив күнекмәләрне үзләштерү дәрәҗәсе) тикшерә.

Вариантлар имтиханда катнашучыга һәм киң җәмәгатьчелеккә төп дәүләт имтиханы эшенең төзелеше, биремнең үзенчәлеге, аның формасы, катлаулылык дәрәҗәсе турында фикер йөртергә мөмкинлек бирә. Бу вариантлардагы биремне үтәүнең бәяләү критерийлары җавапның тулылыгы һәм дөрес язылышы таләпләре турында күзаллау тудыра, чыгарылыш сыйныф укучыларының төп дәүләт имтиханына әзерлек осталыгын булдыра.

Эшне үтәү өчен күрсәтмә

9 нчы сыйныфны тәмамлаучы укучыларга туган (татар) төп дәүләт имтиханын башкару өчен 3 сәгать 55 минут вакыт бирелә. Бирем 1 өлештән тора. Укучылар тәкъдим ителгән текстны 2 тапкыр тыңлыйлар. Беренче тапкыр тыңлаганнан соң, уйлану һәм караламада эшләү өчен 5 минут вакыт бирелә. Текстны икенче тапкыр тыңлаганнан соң, изложение язу эше башлана. Изложение биремдә күрсәтелгән проблемага бәйле сочинение элементлары

белән киңәйтелә. Укучылар әлеге проблемага бәйле иҗади фикер йөртергә һәм үз фикерләрен дөрес, логик эзлеклелектә формалаштырырга тиеш.

Язма эшне башкару барышында орфографик сүзлекләрдән файдаланырга рөхсәт ителә.

Караламадагы язулар тикшерелми!

Язма эш махсус төзелгән критерийлар буенча бәяләнә. Язма эшне хаталарсыз башкарып, югарырак балл җыярга тырышыгыз.

Сезгә уңышлар телибез!

1 нче вариант

Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм таныр-лык итеп языгыз.

Кыр кәҗәләре

Көтүче кыш көнендә урманда бер агач төбеннән берничә Кыр кәҗәсе тапты.

Менә, Көтүченең уенча, байлык! Менә хәзинә!.. Бу кадәр байлык һәм бәхеткә ничек чыдарга кирәк? Көтүче, мескин, ихтыярсыз, күзеннән яшь чыгара-чыгара, Ходайга шөкер итә иде.

Көтүчегә куанырга, шөкер итәргә юл да бар: бу Кәҗәләрдә Хуҗаның нигездә катышы юк. Боларның йонын да Көтүче үзе кыркачак, сөтен дә үзе савачак...

Ләкин эшнең бер җире генә килешмәде: ул да булса, вакыт кыш көне булганлыктан, бу Кыр кәҗәләрен ашатырга печән булмавы яки азлыгы иде.

Күп уйлар, күп фикерләрдән соң, безнең Көтүче моңа да акыл тапты: ул үзенең Сарыкларының печәнен әкрен-әкрен бу кунак Кәҗәләргә ашата башлады. Көтүченең күңеле ачылган, кунакларны сөя, башларын сыйпый; Кәҗәләре янына көненә йөз мәртәбә генә килә торгандыр!

Кайвакыт бу кунакларның азыгына иске хуҗа — Сарыклары сузыла башласалар, бичараларның башларына сугып җибәрә иде.

Мөгаен, яңа кунакларның зарары булса кирәк, яз башына чыкканда, Сарыкларның коры сөякләре генә калган иде.

Берзаман көннәр җылынып, урманнарда яшеллекләр генә күренә башлаган иде, Кыр кәҗәләре — барчасы берьюлы, Көтүчегә койрыкларын гына күрсәтеп, урманга качтылар.

Көтүче! Мин сиңа бер сүз әйтим, хәтерең калмасын: син, Кыр кәҗәләрен сыйлап азык бетергәнче, үз Сарыкларыңны яхшы сакласаң булмасмы иде?

(Г.Тукай) (185 сүз)

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Көтүче берничә Кыр кәҗәсен тапты.
2	Көтүче Кәҗәләргә Сарыкларының азыгын ашатты.
3	Яз җитүгә, Кыр кәҗәләре урманга качтылар.
4	Көтүчегә киңәш буларак әйтелгән сүз.

2 нче вариант

Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм таныр-лык итеп языгыз.

Шагыйрь, тезләренә таянган килеш, бераз уйланып утыра, аннары тагын сорап куя:

— Юлкотлыны сагынасыңмы?

— Сагынам, улым!

— Әйе, халык матур уйлаган, авылына, җиренә, суына матур исемнәр бирә белгән. Юлкотлы! Юлың котлы булсын, Акъәби! — дип әйтәсе килеп тора.

— Безнең ерак бер бабаебызның исеме Юлкотлы булган диләр. Аның кышлавын «Юлкотлы кышлавы» дип йөрткәннәр. Тора-бара авылга да шул исем күчкән.

— Ә, шулаймыни? — ди шагыйрь, кызыксынып, һәм карчык-тан ипләп кенә аның кыз чакларын, кайчан, ничә яшендә кияүгә чыгуын, туйларның ул заманда ничек узуын, шул чактагы йолала-рны, уеннарны, җырларны сорашырга тотына. Акъәби, еш кына тыны кысылса да, үзенең истәлекләрен, күргән-белгәннәрен иренмичә сөйли, ә шагыйрь аны бик игътибар белән тыңлап утыра... Карчык сөйләп бетергәч тә әле, ул ни дә булса әйтергә ашыкмый, тик бераздан гына үзенең берәр эчке уен раслагандай әйтеп куя:

— Әйе... узган гомер кире кайтмый, сулар үргә акса да!.. Шулай ди җыр, сулар үргә акса да ди, усал әйтә! Берсе дә — узган гомер дә, үтеп киткән тормыш та кире борылып кайтмаячак. Син дә, әбекәем, моның белән килешә торгансыңдыр?

— Килешмичә, нихәл итәсең инде...

— Юк, син дөресен әйт, син олы кеше, бәлки борынгы тормыш сиңа кадерлерәктер, син аны сагына торгансыңдыр?..

— Хәзергесе начар булса, сагыныр идем, — ди карчык, уйланып кына. — Хәзергесе, Аллага шөкер, әйбәт бит.

Шагыйрь аңа күзләрен тутырып карый.

— Шулаймы?.. Син дөньяны таный беләсең икән, әбекәй, яшә, яшә!.. Ләкин сагыныр нәрсәләр дә юк түгел бит. Әнә шул син сөйләгән халыкның матур йолалары — бәйрәмнәре-туйлары, уеннары-җырлары — берсе дә онытылмаска тиеш, минемчә... Халыкның буыннан-буынга күчеп килгән рухи байлыгы бит алар барысы да... Дөрес, яңа заман яңа байлыклар тудыра, ләкин искенең дә яхшысын саклый белергә кирәктер ләбаса!

— Борчылма, улым, — ди карчык, сабыр гына. — Халыкныкы халыкта саклана, югалмас!

(Ә. Еники) (265 сүз)

Чыганак: Әмирхан Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәреннән өзек.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Халык авылына, җиренә, суына матур исемнәр бирә белгән.
2	Шагыйрь Акъәбидән үткәнен сораштыра.
3	Акъәби бүгенге көненнән канәгать.
4	Халыкның матур йолалары — бәйрәмнәре-туйлары, уеннары-җырлары — берсе дә онытылмаска тиеш.

3 нче вариант

Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм таныр-лык итеп языгыз.

Татлының да татлысы булган төш керде аңа. Имеш, таң вакыты. Зур булмаган кәҗә көтүе биек-биек таулар, дәү-дәү ташлар арасында йөри икән. Кәҗәләр арасында аның әнкәсе дә бар. Ягымлы күзләреннән, озын кара мөгезләреннән һәм кояшлы көндә үзеннән берөзлексез көмеш нурлар балкытып торган зифа гәүдәсеннән таныды аны Микәй. Ул кыя читендәге олы бер таш өстенә менеп баскан да ерак-еракларга, офык читендәге мәһабәт ак тауларга карап тора. Шунда алгы аяклары белән ташны тырнап торган әниләре бәтиләрен үзе янына чакырды. Микәй, туган энесе белән икәү, дөньяларын онытып, таштан ташларга сикереп куышлы уйнап йөри иде. Чакырганны күреп, алар шунда ук уеннарын ташлап әнкәләре янына томырылып килделәр, һәм әнкәләренә охшарга тырышып, аның белән янәшәгә, кыя читенә килеп бастылар.

— Мә-ә-ә, — дип, дәште әнкәләре тыныч кына. — Каршыдагы үзәнлек аръягындагы ак калкулыкны күрәсезме?..

— Ми-ә-ә, — дип, бер-берсен бүлдереп җавап кайтарды бәтиләр. —Күрәбез, күрәбез...

— Шул ак калкулыкның да аргы ягында ап-ак болытларга ашкан ак кыялар бар...

— Ә ул ап-ак болытларга җиткән ак кыяларда ни бар?

— Бәхет, бәтиләрем. Бәхет...

— Бәхет ул ни була, әнкәбез?..

— Бәхет ул — тыныч лык һәм ирек дигән сүз... Әнә, ул ак кыяларда сезнең бәхеткә һичкем кул сузмас, бәтиләрем. Шунда гына сез рәхәтләнеп иректә йөри алырсыз.

— Монда да бик тыныч, иркен ич, әнкәбез... — Тыныч иде...

— Нигә «иде»?..

— Кеше эзләре, бәтиләрем!.. Кеше эзләре күренә бу кыяда.

— Ә кеше ул нинди була?

— Кешеме? — дип, ничек әйтергә белми уйга калып торды әнкәләре.

— Әйе, әйе, кеше... Ул нинди була, әйт инде, әйт, әнкәбез?.. — дип, тынгысызланды алар.

— Ул ике аяклы һәм мең мәкергә ия!.. Аю-бүредән качып була, ә кешедән качу кыен, бәтиләрем.

Юк, явыз түгел кешеләр! Алар аны үзен тоткын иткән җәймәдән чыгардылар. Алар аны үзен тоткын иткән җәтмәдән чыгардылар. Сукмый-какмый өйләренә алып кайттылар да ерак юлга озаттылар. Явыз түгел кешеләр. Алар аны ашатты, эчертте, җылы урында тотты, рәнҗетмәде, үз итте, кадерләде. Ничек итеп кешеләр турында начар уйлый алсын соң ул?!

Әнкәсенең кешеләргә булган үпкәсенең серен күпме генә ачыкларга тырышмасын, Микәй аңлый алмады.

(Р.Мөхәммәдиев) (309 сүз)

Чыганак: Ринат Мөхәммәдиевның «Ак кыялар турында хыял» повестеннан өзек.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Кәҗә көтүе ташлар арасында йөри.
2	Бәхет — ак кыялар җирендә.
3	Ирек һәм кеше.
4	Микәй һәм кеше.
5	Әнкәсенең кешеләргә үпкәсен Микәй аңламады.

4 нче вариант

Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң, текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм таныр-лык итеп языгыз.

Тау өстеннән караганда, авыл ак түбәләре белән уч төбендәге кебек җәйрап ята. Сирәк кайтылганга күрә, үзгәрешләр бигрәк тә нык сизелә. Ә мин, җүләр, һаман әле иске урамнарны, салам җүбәле өйләрне юксынам. Малай чакта үзем ачып кергән капка тавышлары да хәтердән җуелмаган. Зур шәһәрләрдә, чит-ят илләрдә патшалар яшәгән, корольләр салдырган затлы сарайларны карап йөргәндә, мин арыш саламы ябылган гади өйләрен юксынып күз алдыма китерәм. Шул чакта сиздерми генә артыңнан килеп кемдер чабуыңнан тарта, борылып карасаң — артыңда елмаеп, малай чагың басып тора. Көзге кебек идәндә ул ялан аягыннан яфрак-яфрак дымлы эзләр калдырып, сине үзе белән иртә дә очыртып кына диңгезләр, кыятаулар аша салам түбәле өйгә алып кайта.

Кешеләр генәме, сулар да бит туган ягына кире кайта. Диңгезгә барып җиткән чишмә сулары, парга әйләнеп, болыт хасил итәләр дә, яңгыр булып, туган якка кайтып явалар. Билгеле, бу — табигатьнең ашкыну һәм сагыну арасындагы мәңгелек әйләнеше.

Алтын Болак авылы үзенең тыйнак таулары, карт өянке тамырларын сыйпап аккан инеше белән эссе җәй хозурлыгында изрәп ята. «Кадерле көннәрең онытылып калмаганмы монда, ашыгып үтеп китмәгәнсеңме, мәрхәмәтле авылдашларың яныннан? — дип кисәтәләр сыман алар. — Дөньяның фани икәнлеген онытып, рәнҗетмәдеңме берәрсен? Бәгыреңне йомшарту өчен, кабер өстендәге тирәкләрнең җилдә пышылдавын тыңлый белергә өйрән. Соңыннан гына үкенү-сызлануларны үлгәннәр кичермиләр, кеше изгелеккә, җылы сүзгә исән чакта мохтаҗ.»

(М.Галиев) (202 сүз)

Чыганак: Марсель Галиевнең «Нигез» повестеннан өзек.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Мин өйләрне күз алдыма китерәм, юксынам.
2	Сулар да бит туган якларына кире кайта.
3	Кеше изгелеккә, җылы сүзгә исән чакта мохтаҗ.

5 нче вариант

Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм таныр-лык итеп языгыз.

Мактанчык чәйнек

Булган, ди, юан корсаклы, кәкре корсаклы, кәкре борынлы, түгәрәк аслы бер чәйнек. Үзе кебек үк ялтыравыклы савыт-саба арасында иң һавалысы, мактанчыгы шул, ди. Шулай булмыйча? Хуҗабикә аны көненә ничәмә-ничә тапкыр кулына алып, утка куя бит. Чәйнексез бер көн дә яши алмый.

Савыт-сабалар чәйнеккә бик кызыгалар. Их, без дә Хуҗабикәбезгә шулай кирәк булсак икән, диләр. Чәйнек аның саен масая, мактана, бүксәсен киереп, бөтен уйгә пар чәчеп утыра.

Бик кыю чәйнек ул, кайчакларда хәтта Хуҗабикәне дә дә биет-кәли. Кайнап чыгуга уттан алырга оныттымы, чәйнек ачуыннан ярсый, котыра башлый. Борыныннан да, капкач астыннан да пош-кыра-пошкыра пар җибәрә, сызгыра, капкачын күтәреп-күтәреп бәрә.

Шулай көннең-көнендә мактала торгач, чәйнекнең масаюы шул дәрәҗәгә җитте ки, ул инде Хуҗабикәне бар дип тә белми башлады. Кайчан гына килеп тотынмасын, капкачыннан чыжлап пар бөркеп, кулын пешерә иде. Тәмам аптырады Хуҗабикә, күпме еллар бик бирелеп хезмәт иткән чәйнегенең кинәт шулай үзгәрүен һич кенә дә аңлый алмады. Гел мактаудан масаюын белми иде ул аның. «Искердең ахры, чәйнеккәем», — дип көрсенде Хуҗабикә.

Өйрәнгән киемнән генә түгел, ияләшкән савыт-сабадан да аерылуы кыен. Ләкин нихәл итмәк кирәк?! Көннәрдән бер көнне Хуҗабикә ялт итеп торган өр-яңа чәйнек күтәреп кайтты. Ә мактанчык чәйнекне, калдык суын түгеп, шкаф астына, иске-москы арасына тыгып куйды.

Хәзер инде плитә өстен әле масаерга өлгермәгән өр-яңа чәйнек бизи. Мактанчык чәйнек, түбәтәен кыңгыр салып, язмышыннан зарлана-зарлана он капчыгы өстендә утыра.

(Р.Хафизова) (213 сүз)

Чыганак: Роза Хафизованың «Мактанчык чәйнек» хикәясе.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Чәйнекне Хуҗабикә еш кулына ала.
2	Чәйнек масая башлый.
3	Хуҗабикә яңа чәйнек алып кайта.

6 нчы вариант

Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм таныр-лык итеп языгыз.

Авылдагы әниләрнең иң матуры — минем әнкәй. Бу уемны мин Нәҗип белән Наилгә дә әйттем.

— Минем әни матуррак! — диде Наил җавабында. Нәҗип тә бәхәсләшә:

— Иң матуры минем әни! — ди.

Бәхәсләшә торгач, ул көнне без сугыша яздык. Ярый әле, шунда безне эзләп су буена әниләребез килде. Аларның иң матуры минем әнкәй иде. Чынлап та, күзләре аның яшел иде... Ул чакта мин шуны да күрдем: Нәҗипнең әнисе — зәңгәр күзле, Наилнең әнисе — кара күзле икән. Безенең әниләребез дә дуслар. Алар эшкә бергә йөриләр. Авыл кырларында аларның эшләре күп шул — санап чыгарлык түгел. Җирләрне сөрәсе, сөрелгән җиргә бодай чәчәсе...

Без өч малай җәйләрнең яшел җилкәсендә, кышларның ак түшендә бергә аунап үстек. Тиздән әнкәйләргә ярдәм итә башладык. Аларның хәлен аңладык. Безнең әткәйләр юк, сугышта үлгәннәр. Авылның бөтен эше әнкәйләргә калган. Ашарларына аш, киерләренә кием җитми. Өстәвенә — кышлары салкын. Шуңа күрә аларга кыен.

Шундый кыен кышларда моңланып әнкәйнең әкрен генә җырлаганын хәтерлим. Әкрен генә елаганын да күп күрдем. Ул елагач, миңа күңелсез. Ә минем әнкәй... Минем әнкәй барыбер матур. Инде аның күзләре ак кышның яшел күзләре шикелле. Әйе, ак кышның яшел күзләре миңа:

— Күңелсезләнмә! — диләр. — Тиздән җылы, яшел җәй киләчәк! — диләр.

Ул кышлар Наил белән Нәҗипкә дә шулай, үз әнкәләренең күзләре аша караганнардыр, шулай әйткәннәрдер.

Без яшәргә килгән бу җирдә төсләрнең исәбе-хисабы юк. Тик дөньяда иң матур төс, иң ачык төс итеп һәркем үз әнисенең күзләре төсен күрәдер. Җәй дә, кыш та шулайдыр ул.

(Р. Мингалим) (227 сүз)

Чыганак: Рөстәм Мингалимнең «Яшел күзле әнкәем» хикәясеннән өзек.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Өч малай да үз әнисен иң матур дип саный.
2	Әниләргә бик авыр.
3	Әнинең яшел күзләре җылы, яшел җәй җитәчәк дип юата.
4	Һәркемгә дөньяда иң матур төс — әнисенең күзләре төсләре.

7 нче вариант

Текстны тыңлагыз һәм изложение языгыз. Изложениедән соң текстта булган вакыйгаларга үз фикерегезне өстәп языгыз. Фикерегезне раслау өчен, укыганнарыгызга, шулай ук белемегезгә һәм тормышта күзәткән күренешләргә таянып, 2 дәлил китерегез. Киңәйтелгән изложениенең күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш. Изложениене чиста һәм таныр-лык итеп языгыз.

Бер вакытны эт шуңа игътибар итте: әни карчык улы кайтыр алдыннан гел стенадагы зур сәгатькә күз сала да өстәл әзерләргә керешә. Күп тә үтми хуҗа да кайтып керә. Тора-бара эт төшенде: әби дә, аның шикелле үк, хуҗаны көтә икән. Хуҗаның кайтыр вакыты якынлаша башлады исә, ул үзенә тынгы таба алмый, балкон ишегенә килә, ачыгыз дигәндәй, чиный. Менә әби ишекне ача һәм эт балконга омтыла, югары каттан аска, урамга карый — хуҗаны көтә.

Ә бер көнне өй янына кайтып җиткән хуҗаны ниндидер бер адәм туктатты. Ул шактый сизелерлек чайкала, каты кычкыра иде.

Хуҗаның һаман шул кеше белән торуы этне борчуга салды. Ул, муенын сузып, аска карап торды, бер-ике тапкыр өреп тә алды, нәфрәт белән ят кешене күзәтте. Эт аңлады: хуҗаны ул җибәрми.

Этнең өргәнен ишетеп, хуҗа өскә карады. Ул ярдәм сорый кебек иде.

Ә теге адәм һаман кулларын болгый, нидер кычкыра, кызып китеп, хуҗаның якасына үк үрелә. Ят кеше аның хуҗасына кул да күтәрә түгелме соң?!

Бу мизгелдә эт өчен шушы адәмнән дә явыз кеше юк иде. Аның бөтенләй түземе бетте... Шунда ул, үзе дә сизмәстән, өстәл өстенә сикереп менде, аннан култыксага үк үрелеп, аска карады һәм ... җиргә очты.

...Эт, асфальтка бәрелеп, бер-ике тыпырчынды да тынып калды. Ирләр берни адламадылар, тораташтай катып, эткә төбәлделәр. Бер-ике секундтан чырае качкан хуҗа исенә килде, эткә таба иелде.

— Егылып төште, бичара, — диде ят кеше, кинәт айнып китеп. — Синеке мәллә?

Хуҗа эндәшмәде.

(С.Шәмси) (227 сүз)

Чыганак: Солтан Шәмсинең «Нәни дус» хикәясеннән өзек.

Киңәйтелгән изложение өчен текст турында белешмә	
Абзац номеры	**Микротемалар (мәгънәви кисәкләр)**
1	Әни кеше улын, эт хуҗасын эштән көтеп ала.
2	Хуҗа балкон астында гына кем беләндер сөйләшә.
3	Эт түзмәде, балконнан сикерде.

Язма эшне бәяләү критерийлары

1нче таблица

№	Критерий	Балл
ИК1	**Изложениенең эчтәлеге**	**2**
	Укучы тыңланган текстның эчтәлеген тулы ачкан, анда яктыртылган барлык мәсьәләләр язмада урын алган.	**1**
	Текстның эчтәлеге ачылган, әмма бер микротема төшеп калган (яки өстәлгән).	**0**
	Текстның эчтәлеге ачылган, әмма бердән артык микротема төшеп калган (яки өстәлгән).	
ИК2	**Изложениенең мәгънә бөтенлеге, бәйләнешле сөйләм һәм аның эзлеклелеге**	
	Укучының эшендә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә: — логик хаталар юк, эзлеклелек бозылмаган; — текст кызыл юлларга дөрес бүленгән.	**3**
	Эштә мәгънә бөтенлеге, сөйләмнең бәйләнешле һәм эзлекле булуы күзәтелә, әмма бер логик хата бар яки кызыл юлны билгеләүдә бер хата бар.	**2**
	Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган, әмма ике логик хата яки кызыл юлны билгеләүдә ике хата җибәрелгән.	**1**
	Эштә коммуникатив (аралашуга караган) мәгънә сакланган, әмма икедән артык логик хата яки кызыл юлны билгеләүдә икедән артык хата җибәрелгән.	**0**
ИК3	**Эшнең композицион бөтенлеге**	
	Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, текст төзүдә хаталар юк.	**2**
	Эш композицион яктан бөтен һәм төгәлләнгән, ләкин текст төзүдә 1 хатасы бар.	**1**
	Текст төзүдә 2 яки күбрәк хатасы бар.	**0**
ИК4	**Дәлил-мисалларның булуы**	
	Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (2дән ким булмаган дәлил китергән, шуларның берсе	**3**

	матур, публицистик яки фәнни әдәбиятка карый).	
	Укучы фикерен белдергән, дәлилләгән (белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып, 2дән ким булмаган дәлил китергән), яки матур, публицистик яки фәнни әдәбиятка караган 1 генә дәлил китергән.	**2**
	Укучы фикерен белдергән, белеменә, тормыш тәҗрибәсенә таянып дәлилләгән (1 дәлил китергән).	**1**
	Укучы фикерен белдергән, ләкин дәлилләмәгән, яки укучы фикере формаль рәвештә генә (мәсәлән, “Мин автор фикере белән риза / риза түгел”) бирелгән, яки укучы фикере язмада бөтенләй чагылыш тапмаган.	**0**
ИК1-ИК4 күрсәткечләре буенча изложение өчен җыела торган иң югары балл		**10**

Язма эшнең грамоталылыгы һәм аның фактик төгәллеге аерым бәяләнә.

2 нче таблица

№	**Укучы сөйләменең грамоталылыгын һәм фактик төгәллеген бәяләү критерийлары**	
ГК1	**Орфографик нормаларның үтәлеше**	
	Орфографик хаталары юк яки хатасы 1 дән артык түгел.	**2**
	2–3 хата җибәрелгән.	**1**
	Хаталарының саны 4тән артык.	**0**
ГК2	**Пунктуацион нормаларның үтәлеше**	
	Пунктуацион хаталары юк яки хатасы 2дән артык түгел.	**2**
	3–4 хатасы бар.	**1**
	Хаталарының саны 5 тән артык.	**0**
ГК3	**Грамматик нормаларның үтәлеше**	
	Грамматик хаталары юк яки 1 хатасы бар.	**2**
	2 хатасы бар.	**1**
	Хаталарының саны 3 тән артык.	**0**
ГК4	Сөйләм нормаларының үтәлеше.	

	Сөйләм хаталары юк яки хатасы 2дән артык түгел.	**2**
	3–4 хатасы бар.	**1**
	Хаталарының саны 5тән артык.	**0**
ФК1	Язма сөйләмнең фактик төгәллеге.	
	Материалны язмада бирүдә, шулай ук аңлауда һәм терминнар кулланылышында фактик хаталар юк.	**2**
	Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 1 хата бар.	**1**
	Материалны язмада бирүдә яки терминнар кулланылышында 2 хата бар.	**0**
ГК1-ГК4, ФК1 критерийлары буенча изложение өчен иң югары балл		**10**

Грамоталылыкны бәяләгәндә, изложениенең күләмен исәпкә алырга кирәк. Язма эшнең гомуми күләме 150 сүздән ким булмаска тиеш.

2нче таблицада китерелгән нормативлар гомуми күләме 150 һәм 150 сүздән күбрәк булган изложениеләрне тикшерү өчен кулланыла.

Әгәр изложениенең гомуми күләме 100–149 сүз булса, ГК1-ГК4 критерийлары буенча 1 баллдан артык куелмый:

ГК — 1 буенча орфографик хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК — 2 буенча пунктуацион хаталар булмаса яки 1 тупас булмаган хата булганда 1 балл куела;

ГК — 3 буенча грамматик хаталар булмаганда 1 балл куела;

ГК — 4 буенча сөйләм хаталары булмаганда 1 балл куела.

Әгәр изложениенең гомуми күләме 75 сүздән артмаса, мондый эшләргә ГК1-ГК4 критерийлары буенча 0 балл куела.

Дәүләт йомгаклау аттестациясен тулаем башкару барышында җыярга мөмкин булган максималь балл — 20.

Имтихан эше өчен түбәндәге билгеләр куела:

0–5 балл — «2»ле билгесе;

6–10 балл — «3»ле билгесе;

11–15 балл — «4»ле билгесе.

Искәрмә: бу очракта укучы грамоталылык өчен (ГК1–ГК4 критерийлары) 5 баллдан кимрәк балл җыймаска тиеш. Әгәр укучы ГК1–ГК4 критерийлары буенча 5 баллдан кимрәк балл җыйса, «3»ле билгесе куела. 16–20 балл — «5»ле билгесе. Искәрмә: бу очракта укучы грамоталылык өчен (ГК1–ГК4 критерийлары) 10 баллдан кимрәк балл җыймаска тиеш. Әгәр укучы ГК1–ГК4 критерийлары буенча 10 баллдан кимрәк балл җыйса, «4»ле билгесе куела.

ЭЧТӘЛЕК

ТАТАР ТЕЛЕ. 81 нче КОД.....3

ТАТАР ТЕЛЕ. 82 нче КОД.....24

Уважаемые коллеги, приглашаем к сотрудничеству!

СОВРЕМЕННОЕ ОБРАЗОВАНИЕ: АКТУАЛЬНЫЕ ВОПРОСЫ И ИННОВАЦИИ

Свидетельство о регистрации СМИ: ЭЛ № ФС 77-74813

(выдано Федеральной службой по надзору в сфере связи, информационных технологий и массовых коммуникаций)



Территория распространения:
Российская Федерация и зарубежные страны
Периодичность: четыре раза в год
Опубликованные материалы будут размещены в Научной электронной библиотеке (**e-library.ru**) и войдут в базу данных **Российского индекса научного цитирования (РИНЦ)**
Контактное лицо: Шайхутдинова Галия Айратовна
Адрес электронной почты: smi@irort.ru

Подробная информация для авторов http://irortsmi.ru/node/3

АКТУАЛЬНАЯ ПЕДАГОГИКА



Территория распространения:
Российская Федерация и зарубежные страны
Свидетельство о регистрации: ПИ №ФС77-75641 от 26 апреля 2019 г.
Материалы публикуются на русском и татарском языках
Контактное лицо: Абдулаев Валерий Анатольевич
Номер телефона редакции: 8 937610 37 60
Адрес электронной почты: vabdulaev@inbox.ru







Институт развития образования
Республики Татарстан
420015, Казань, Большая Красная, 68
(843) 236-65-63, 236-62-42
irort2011@gmail.com